**СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ АКЪЯР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 22,
Акъяр авылы,423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 30 декабре №29-97

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының карарын кире кагу турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә һәм җирлекләрнең территорияләрен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында имзаланган килешүләр булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге Советының 31.08.2022 ел, №25-84 нче карарын кире кагарга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне даими рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм Ленино авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерү буенча депутатлар комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы Д.С.Гайнуллин